**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4387**
**04.09.2020**

Башкарма комитетның 2020 елның 14 апрелендәге 1828 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү өчен ординатура программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарына компенсация алу хокукына конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.25 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 14 апрелендәге 1828 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү өчен ординатура программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарына компенсация алу хокукына конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктта «1 августтан 15 августка кадәр» сүзләрен «24 августтан 31 августка кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

2) 18 пунктта:

- беренче абзацта «1 августка кадәр» сүзләрен «24 августка кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

- 2 пунктчада «аккредитация» сүзеннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

3) 19 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) югары медицина белеме турында дипломның уртача баллы:

- 4,5 тән 4,9 га кадәр (10 балл);

- 4,0 дән 4,4 кә кадәр (8 балл);

- 3,5 тән 3,9 га кадәр (4 балл);».

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Ф.Ш. Салахов